**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 87-17 «26» июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2022 елның 14 апрелендәге 83-16 номерлы «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының _ җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезләмәсе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәреСоветы
**карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2022 елның 14 апрелендәге 83-16 номерлы «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының _ җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезләмәсе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны тәэмин итү, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9.9. Мөрәҗәгатьне караганда, мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка фаш итү рөхсәт ителми. Шулай ук гражданның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү факты һәм аны карау нәтиҗәләре турында мөрәҗәгатьләрне карауга турыдан-туры катнашы булмаган затларга хәбәрителергә тиеш түгел. Мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне фаш итү, язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрү булып тормый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин